| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 нчы октябрь, 2020 ел Багай ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Багай авыл җирлегенең Араслан авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсә , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 маддәсә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 17 ноябрена 11 сәгать 00 минутка , Араслан сөт-товар фермасы бинасында ял итү бүлмәсендә: Араслан авылы, Араслан сөт-товар фермасы адресы буенча урнашкан , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2020 елның 17 ноябрена 13 сәгать 00 минутка, Араслан авыл клубы бинасында: Араслан авылы, Чапаев урамы, 18 йорт, адресы буенча урнашкан , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Араслан торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Багай авыл җирлеге Араслан торак пункт территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- балалар мәйданчыкларын төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру::*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
- су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагы артскважиналарын куллану буенча санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар)

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту. »

« РИЗА» «КАРШЫ»

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова